# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законны гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында" 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләр чоры чикләрендә гамәлдә була һәм яңа сайланган Татарстан Республикасы Президенты алдында үз вәкаләтләрен туктата. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының үз вәкаләтләрен туктатуы турындагы карар Татарстан Республикасы Президенты үз вазыйфасына керешкән көндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә.";

2) 18 статьяның 2 пунктында "вәкаләтләр яңа бирелгән" сүзләрен "сайланган" сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1-2, № 4 (I өлеш); № 12; 2011, № 5) "вәкаләтләр бирү" сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында" 1991 елның 4 июлендәге 1141-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 3; 2005, № 6 (I өлеш); 2010, № 3);

2) "Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында" 2004 елның 25 мартындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (IV өлеш);

3) "Сайлаулар һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм "Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуын туктатып тору турында" 2005 елның 31 мартындагы 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 3 (I өлеш); 2007, № 5);

4) "Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында" Татарстан Республикасы Законындагы 1 статьяның гамәлдә булуын туктатып тору хакында" 2005 елның 15 июнендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 6 (I өлеш).

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2012 елның 14 июле
№ 54-ТРЗ